**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

**ТУРАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ**

**КАРАРЫ**

18.08.2021 № 8

**"Территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында»**

2004 нче елның 29 нчы декабрендәге 190-ФЗ номерлы РФ Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 нчы елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлеге Уставы нигезендә, җәмәгатьчелек фикерен ачыклау һәм территорияне планлаштыру проектлары һәм «РИТЭК»АҖ объектын проектлаштыру һәм төзү өчен территорияне межалау проектлары буенча тәкъдимнәр кертү максатында

Карар бирәм:

1. Территорияне планлаштыру проекты буенча һәм территорияне межалау проекты буенча Татарстан Республикасы Менделеевск районы Турай авыл җирлегенең административ чикләрендә урнашкан «ТПП ТатРИТЭКнефть» Ольгин нефть ятмасының 2412 “Куст скважиналарын төзекләндерү” объектын проектлау өчен 18.09.2021 нче елны гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Менделеевск районы Турай авыл җирлеге администрациясе белгече Рәхимова Әлфирә Минирафисовнаны халык алдында тыңлаулар оештыру һәм үткәрү, ачык тыңлаулар беркетмәсен һәм авыл халкына гавами тыңлаулар мәсьәләсе буенча мәгълүмат бирү чарасы беркетмәсен алып бару өчен җаваплы зат итеп билгеләп куярга.

3. Татарстан Республикасы Менделеевск районы Турай авыл җирлегендә яшәүчеләргә, территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты буенча башка кызыксынган затларга Татарстан Республикасы Менделеевск районы Турай авыл җирлеге администрациясе бинасын (Татарстан Республикасы, Менделеевск районы, Турай авылы, Центральная урамы, 11 а йорт) үткәрү урыны итеп билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Менделеевск районы Турай авыл җирлегендә яшәүчеләргә, башка кызыксынган затларга мәгълүмат бирү буенча чаралар 18.09.2021, 9.00 дән 10.00 сәгатькә кадәр ачык тыңлаулар буенча билгеләргә.

5. Әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты буенча кызыксынган затлардан искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кабул итүне Татарстан Республикасы Менделеевск районы Турай авыл җирлеге администрациясендә Рәхимова Әлфирә Минирафис кызы 18.08.21 елда түбәндәге адрес буенча тормышка ашырырга: Татарстан Республикасы, Менделеевск районы, Турай авылы, Центральная урамы, 11 а йорт.

6. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Авыл җирлеге башлыгы** **А. М. Рәхимова**